| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>***БУА ШӘҺӘРЕ***<br>***БУА***<br>***МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ***<br>***БАШЛЫГЫ*** | **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>***ГЛАВА***<br>***ГОРОДА БУИНСКА***<br>***БУИНСКОГО***<br>***МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА*** |

**КАРАР**
**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

« 21 » май 2021 ел № 9

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Татар Буасы, Түбән Наратбаш һәм Ырынгы авыл җирлекләре чикләре белән чиктәш җирдә муниципаль берәмлек чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык (гавами) тыңлаулар үткәрү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2020 елның 15 маендагы 3-53 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү турында» карары нигезендә, Буа шәһәрендә яшәүчеләрнең ачык тыңлаулар уздыру юлы белән Буа шәһәре муниципаль берәмлек чикләре турындагы проект буенча фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы, Буа шәһәре, Жорес ур., 110А йорт, (2 кат, утырышлар залы) адресы буенча Буа муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында 2021 елның 22 июненә 10.00 сәгатьтә Буа шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен Татар Буасы, Түбән Наратбаш һәм Ырынгы авыл җирлекләре чикләре белән чиктәш җирдә үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрүне билгеләргә (1нче кушымта нигезендә).

2. Ачык тыңлауларда фикер алышына торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2021 елның 21 июненә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Буа ш., Жорес ур., 110 А йорт, 9 бүлмә, Буа муниципаль районы Башкарма комитеты, телефон 3-11-93.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә, Татар Буасы, Түбән Наратбаш һәм Ырынгы авыл җирлекләре чикләренә керүче җир кишәрлекләрен «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенә кертү юлы белән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» һәм «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларны әзерләү һәм уздыру буенча эшче төркем составын расларга.

4. Әлеге карар «Знамя» («Байрак», «Ялав») басма-редакция газетасында басылып чыгарга һәм Буа шәһәренең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан ителергә тиеш:

- ТР, Буа шәһәре, Жорес урамы, 110А йорт (Буа муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы);
- ТР, Буа шәһәре, Космовский урамы, 91Б йорт (Буа шәһәре Башкарма комитеты бинасы);
- ТР, Буа шәһәре, Р. Люксембург урамы, 157 йорт (район мәдәният йорты бинасы);
- ТР, Буа шәһәре, Төзелеш урамы, 4 йорт ( «Сахарник» клубы бинасы).

5. «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре», «Татар Буасы авыл җирлеге», «Түбән Наратбаш авыл җирлеге» һәм «Ырынгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләре чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында» 2021 елның 14 маендагы 4 номерлы Буа муниципаль районы башлыгы карарын үз көчен югалткан дип танырга.


6. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы
Буа шәһәре башлыгы Р.Р. Камартдинов

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре башлыгының " 21 " май 2021 ел 9 номерлы карарына 1 нче кушымта

## Карта-схема
границ муниципальных образований
с учетом изменений




Условные обозначения

- граница Республики Татарстан
- граница Буинского муниципального района
- границы муниципальных образований
- А-Б - смежная граница Нижненаратбашского сельского поселения и муниципального образования «город Буинск»
- В-Г - смежная граница Рунгинского сельского поселения и муниципального образования «город Буинск»
- Г-Д - смежная граница Малобуинковского сельского поселения и муниципального образования «город Буинск»
- административные центры поселений
- населенные пункты
- территория муниципального образования «город Буинск» Буинского муниципального района, включаемая в состав территории Нижненаратбашского сельского поселения Буинского муниципального района,
- территория Рунгинского сельского поселения Буинского муниципального района, включаемая в состав территории муниципального образования «город Буинск» Буинского муниципального района
- территория Малобуинковского сельского поселения Буинского муниципального района, включаемая в состав территории муниципального образования «город Буинск» Буинского муниципального района
- территория Нижненаратбашского сельского поселения Буинского муниципального района, включаемая в состав территории муниципального образования «город Буинск» Буинского муниципального района

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре башлыгының " 21 " май 2021 ел 9 номерлы карарына
2 нче кушымта

Буа шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрен Татар Буасы, Түбән Наратбаш һәм Ырынгы авыл җирлекләре чикләре белән чиктәш җирдә үзгәртү мәсьәләсе буенчаачык тыңлауларны әзерләү һәм уздыру буенча эшче төркем составы

1. Галәветдинов Рафис Ягъфәр улы-Буа шәһәре Башкарма комитеты җитәкчесе, эшче төркем рәисе;

2. Зайцева Светлана Анатольевна-Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре башлыгы урынбасары, эшче төркем рәисе урынбасары;

3. Гыйльфанов Ринат Мансур улы – Буа муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура бүлеге җитәкчесе, эшче төркем секретаре.

Эшче төркем әгъзалары:

4. Гыйззәтов Илдус Гашыйк улы – Буа муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы бүлеге башлыгы (килешү буенча);

5. Рахматов Булат Рафаэль улы – Буа муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы ( килешү буенча);

6. Маллямова Ирина Зофяровна – «ТР Буа муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе вазыйфаларын башкаручы (килешү буенча).